**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 17 декабрендәге 5200 номерлы карары**

# Алкоголь продукциясе әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә җирле үзидарә органнарының һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының үзара хезмәттәшлеге тәртибе турында

1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы «Этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү турында»гы федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә **карар бирәм**:

1. Алкоголь продукциясе әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә җирле үзидарә органнарының һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының үзара хезмәттәшлеге тәртибен әлеге карарның кушымтасы нигезендә расларга.
2. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 29 маендагы 5024 номерлы «Алкоголь продукциясе әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә Россия Федерациясе норматив хокукый актларын үтәү чаралары турында»гы карарын гамәлдән чыккан дип танырга.
3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 17 декабрендәге
5200 номерлы карары белән
расланды

**Алкоголь продукциясе әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә җирле үзидарә органнарының һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының үзара хезмәттәшлеге тәртибе**

1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы «Этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу һәм алкогольле продукция куллануны (эчүне) чикләү турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 23 декабрендәге 2220 номерлы «Алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган урыннар янәшәсендәге территорияләр чикләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү кагыйдәләрен раслау турында»гы карары нигезендә, алкоголь продукциясен сату рөхсәт ителми торган оешмалар һәм объектлар, шулай ук алар янындагы территорияләрне исәпкә алу максатыннан.

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгына, Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитеты рәисенә, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе башлыгына ел саен 1 майга кадәр Казан шәһәре Башкарма комитетының Кулланучылар базары комитетына, урнашу урыны адресларын күрсәтеп, күчемсез милек объектлары булган һәм милек хокуклары билгеләнгән тәртиптә теркәлгән белем бирү оешмалары, шул исәптән өстәмә белем бирү оешмалары, өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары, балигъ булмаганнарны укыта торган оешмалар һәм спорт корылмалары исемлеген тапшырырга.

2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Гражданнарны яклау идарәсе башлыгына ел саен 1 майга кадәр Казан шәһәре Башкарма комитетының Кулланучылар базары комитетына, урнашу урыны адресларын күрсәтеп, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә төзелә торган алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган югары куркыныч чыганаклары булган урыннар исемлеген тапшырырга.

3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитеты рәисенә ел саен 1 майга кадәр Казан шәһәре Башкарма комитетының Кулланучылар базары комитетына, урнашу урыны адресларын күрсәтеп, вокзаллар, аэропортлар исемлеген тапшырырга.

4. Тәкъдим итәргә:

4.1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Казан шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсе башлыгына ел саен 1 майга кадәр Казан шәһәре Башкарма комитетының Кулланучылар базары комитетына, Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган исемлек буенча медицина эшчәнлеге төрләреннән тыш, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бирелгән лицензия нигезендә төп (устав) эшчәнлек төре сыйфатында медицина эшчәнлеге яисә төп (устав) эшчәнлек белән беррәттән медицина эшчәнлеге алып бара торган оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр карамагында һәм (яисә) алар файдалануында булган биналар, төзелмәләр, корылмалар, бүлмәләр исемлеген тапшырырга;

4.2. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең Казан территориаль органы башлыгына ел саен 1 майга кадәр Казан шәһәре Башкарма комитетының Кулланучылар базары комитетына Казан шәһәре территориясендә алкоголь продукциясен сату хокукына лицензиясе булган предприятиеләр реестрын тапшырырга.